Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлегенең Урманче поселогы торак пунктында гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

11 ноябрь 2023 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 нче елның 28 нче июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясы нигезендә 2023 нче елның 11 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, «2024 нче елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлегенең Урманче поселогы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә ризамы:

- Урманче поселогында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (су җыю башняларының коймалары)

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 220 (ике йөз егерме) катнашучы кертелгән, 113 кеше гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан, бу 51,4 % ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

ӘЙЕ» позициясе өчен 104 (йөз дүрт) гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; «ЮК» позициясе өчен 9 (тугыз) җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Урманче поселогында гражданнар җыенын – гамәлдә, гражданныр җыены нәтиҗәләрен – дөрес, дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлегенең Урманче поселогында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими рәвештә торак пункт территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән 2024 елда үзара салыма акчаларын 1000 (бер мең) сум күләмендә кертергә.

3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җибәрергә:

- Урманче поселогында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (су җыю башняларының коймалары).

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Ф. Нуруллин